

Яна ел бәйрәмнәре якынлаша. Кvнелле чаралар шомлы хәбәрләр белән тәмамланмасын дисәк, һәммәбез дә уяу булсак иде. Унтугызынчы декабрьдә Мордовия Правительствосы каршында оештырылган котелмәгән гадәттән тыш ситуацияләрне һәм янгынны кисәтv Комиссия утырышы да vтте. Һәр ел балаларнын Чыршы бәйрәмнәре алдыннан Мордовиянен Гадәттән тыш хәлләр инспекторлары бәйрәмнәрне һәм каникулларны исән-имин vткәрvгә әзерлек буенча рейдлар оештыралар.
Шулай, декабрьнен беренче яртысында Яна ел бәйрәмнәре vткәрелә торган урыннарда янгынга каршы корәш буенча профилактик эшләр башкарылган.



Мәсәлән, Мордовия МЧС хезмәткәрләре Торбеево, Зубово-Поляна, Атюрьево, Кочкурово һәм башка районнарында рейдлар булган инде. Ләмберә районы Аксен, Пензятка, Кырви урта мәктәпләрендә, Татар Тавласы, Черемиш топ мәктәбе укытучылары һәм укучылары белән янгыннан эвакуацияләнv кагыйдәләрен vтәv һәм сигнал булгач ничек vзләрен алып барулары тикшерелгән. Шулай ук алар белән «Проведение новогодних мероприятий и соблюдение пожарной безопасности» темасына әнгәмәләр алып барганнар. Мордовиядә беренче тапкыр, МЧС хезмәткәрләренә ярдәм йозеннән, «Свято-Предтеченское» казаклар җәмгыяви

оешманын 25 вәкиле, vз теләкләре белән, янгынга каршы корәш отряды да оештырганнар; укулар да vткәннәр. Хастаханәләр, балалар һәм картлар йортларында да тикшерvләр vткән һәм алар кvзәтvгә куелачак.



Торле пиротехник чараларны куллану очен махсус мәйданнар булдыруны сорала: алар билгеләнгән. Махсус әзерләнмәгән урыннарда пиротехника куллану катгый тыела. Тагы аларны куллану буенча мәгълvматны укырга да, куркынычсызлык кагыйдәләре белән танышырга да кирәк, чонки һәр ел петарда һәм фейерверклардан имгәнv очраклары булып тора.  Гадәттән тыш хәлләр житәкчелеге тарафыннан Яна ел бәйрәмнәре вакытында петарда һәм фейерверкларны куллану буенча чикләvләр кертелә. Аларны сәнәгать биналарыннан, транспорт юллары тирәсеннән, ягулык станцияләреннән - 500 метр, торак йортлардан, авыл хужалыгы сарайларыннан, кеше жыелып торган урыннардан 50 метр читтә генә кулланырга була. Пиротехник эшләнмәләрне урамнан, базарлардан һәм тукталыштагы сату урыннарыннан алмаска кирәк. Алар ачык һавада сату барышында яраксыз хәлгә дә килергә момкин. Котелмәгән шартлаулар да булуы ихтимал, дип кисәтә янгын куркынычсызлыгын кисәтv буенча бvлек житәкчесе. Бәйрәм кичәләрендә аракы эчеп янvчылар да шактый; сак булыгыз! Яна ел бәйрәмнәрегез исән-имин vтсен.
Мордовия буенча Россия МЧС пресс-vзәге информацион материаллары буенча әзерләнде.

**Н. Хәлил**